**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы һәм 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.А. Зәйнетдиновны, М.Р. Зариповны, К.Р. Йосыповны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Габделҗанов Артур Рәшит улын – «Эшлекле Россия» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе рәисен (килешү буенча);

Хаҗиәхмәтов Булат Зөфәр улын – «Яңа проектларга этәргеч бирү буенча стратегик башлангычлар агентлыгы» коммерциячел булмаган автоном оешмасының Татарстан Республикасында вәкиллеге җитәкчесен (килешү буенча);

Шәфигуллин Айрат Радин улын – Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы С.А. Груничевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**

**Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 13 декабрь
№ ПУ-844